Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

“18” ноябрь 2019 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында гражданнар җыенының беренче, икенче этаплары тавыш бирү нәтиҗәләре (нәтиҗәләре) турында» 2019 елның 18 ноябрендәге беркетмәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип таныырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.
2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: территорияне төзекләндерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?” мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.
3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Яңа Суркино авылы, Үзәк урамы, 12А нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Иске Суркино
авыл җирлеге башлыгы Н.В.Леонтьев